СОВЕТ ЗАИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗӘЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

27.08.2020 г. Заинск № 553

**«Зәй муниципаль районында җирле үзидарәнең үз вәкаләтләрен даими нигездә башкаручы депутатларына, сайланулы вазыйфаи затларына, контроль-хисап палатасы рәисенә, муниципаль хезмәткәрләргә хезмәт өчен түләү тәртибе һәм шартлары турында нигезләмә хакында» 2018 елның 13 апрелендәге 279 номерлы Зәй муниципаль район Советы карарына үзгәрешләр кертү турында**

1998 елның 31 июлендәге 145-ФЗ номерлы Россия Федерациясе Бюджет кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, 2016 елның 25 июнендәге 50-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы кодексы, «Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләр башлыкларының, муниципаль берәмлекләр башлыклары урынбасарларының, депутатларның,үз вәкаләтләрен даими нигездә башкаручы җирле үзидарәнең сайланулы органнары әгъзаларының, муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнары рәисләренең айлык акчалата түләү күләмнәрен һәм муниципаль хезмәткәрләрнең вазыйфаи окладларын арттыру турында» 2020 елның 6 августындагы 658 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары нигезендә, Зәй муниципаль районы Уставына таянып, Зәй муниципаль районы Советы

## КАРАР ИТТЕ:

1. «Зәй муниципаль районында үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы җирле үзидарә депутатларының, сайланулы вазыйфаи затларының, контроль-хисап палатасы рәисенең, муниципаль хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү тәртибе һәм шартлары турында нигезләмә хакында» 2018 елның 13 апрелендәге 279 номерлы Зәй муниципаль районы Советы карарына (2018 елның 22 октябрендәге 341 номерлы карар нигезендә кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Әлеге карар белән расланган Зәй муниципаль районында үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы җирле үзидарә депутатларының, сайланулы вазыйфаи затларының, контроль-хисап палатасы рәисенең, муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәте өчен түләү тәртибе һәм шартлары турында нигезләмәнең 2.2 пунктында «11163 сум» сүзләрен «11498 сум» сүзләренә алмаштырырга;

1.2. Әлеге карар белән расланган «Зәй муниципаль районында үз вәкаләтләрен даими нигездә башкаручы җирле үзидарә депутатларының, сайланулы вазыйфаи затларының, муниципаль хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү тәртибе һәм шартлары турында» нигезләмәгә 2 кушымтаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Акчалата бүләкләү күләмнәре

| Вазыйфаның исеме | Акчалата бүләкләү күләмнәре (сумнарда) |
|---|---|
| | 4 төркем |
| Муниципаль берәмлек башлыгы | 31 965 |
| Муниципаль берәмлек башлыгы урынбасары | 28 767 |
| Депутатлар | 15 491 |
| Җирле үзидарәнең сайланулы органнары әгъзалары | 13 165 |
| Контроль-хисап органы рәисе | 28 767 |

».

2. Зәй муниципаль районы җирле үзидарә органнары җитәкчеләренә штат расписаниеләренә һәм локаль актларга тиешле үзгәрешләр кертергә.

3. Авыл җирлекләренең җирле үзидарә органнарына шундый ук карарлар кабул итәргә тәкъдим итәргә.

4. Зәй муниципаль районы Советының оештыру бүлегенә әлеге карарны массакүләм мәгълүмат чараларында бастырып чыгарырга, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Зәй муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

5. Карар 2020 елның 1 октябреннән үз көченә керә.

6. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Зәй муниципаль районы башлыгы урынбасары В. Г. Акатьевка йөкләргә.

**Совет Рәисе** **Р.Г. Кәримов**